ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАРЫ

2021 ел,19 май N11

Каратун авыл җирлеге территориясендә чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру урынын һәм ысулларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында "2021 елның 23 апрелендәге 280 номерлы карары нигезендә" Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында"», Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы торучанлыкны арттыру максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Торак пунктларның гомуми файдаланудагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә учаклар кабызу, махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ризык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук әлеге карарның 2 һәм 3 пунктларында билгеләнгән урыннардан һәм ысуллардан тыш, чүп, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела.

2. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

| № п/п | Торак пункт исеме | Чүп яндыру урыны | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Каратун тимер юл станциясе бистәсе | Торак пунктның көньяк-көнчыгышында (якынча Киров урамы буенча) | Җирлекнең Башкарма комитеты |
| 2 | Каратун ашлык кабул итү пункты бистәсе | Торак пунктның көньяк-көнбатышындарак (якынча Яр урамы буенча) | Җирлекнең Башкарма комитеты |
| 3 | Морзалар авылы | торак пункттан көнбатыштарак (якынча Урман урамы буенча) | Җирлекнең Башкарма комитеты |
| 4 | Свияжский бистәсе | торак пункттан көньяк-көнчыгыштарак ( Яр буе урамы буенча) | Җирлекнең Башкарма комитеты |

3. Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру ысулын билгеләргә - ачык учак .

4. Чүп-чар, үләннәр, яфраклар, агач предметлар һәм башка калдыкларны, материалларны яисә эшләнмәләрне секундына 5 метрдан артмаган җил тизлегендә

яндырырга.

5. Әлеге карар Каратун авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим кертү чорында гамәлдә түгел.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чykkаннан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Каратун авыл җирлеге Башлыгы Р. Р. Сабирҗанова